**Д.Х.Хөснетдинов**

**Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан**

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТАРИХИ ҖЫРЛАРЫНДА ТӨСЛӘР ГАРМОНИЯСЕ

(Тикшеренүләр *11-14-1602а/В* (РГНФ) номерлы грант кысаларында башкарылды)

Татар халкының җыр мирасы күптөрле бизәкләрдән тукылган моңлы дөнья булып күзалдына килә. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенгесе дә тирән уелган.

Җыр - халык лирикасының һәм язма поэзиянең киң таралган төре, сүз-текст белән көй-музыканың үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкаруга исәп ителгән жанр [К.Миңнуллин, 1999: 3].

Җырларның төп вазифасы халыкның һәм аерым бер шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыруга кайтып кала. Шушы үзенчәлегеннән чыгып, бөек шагыйребез Г.Тукай аларны “халык күңеленең көзгесе ” дип атаган [А.Әхмәдуллин, 1990: 238].

Гомумән, халык җыры катлаулы, синтетик музыкаль-поэтик жанр санала. Шушындый синкретик жанрда халык тарафыннан кабул ителгән символ-образлар, символ-сурәтләр белән беррәттән, төс категориясе, “төсле” сурәтләү чаралары аерым бер әһәмиятле урын алып тора.

Төс категориясе, “төсле” сурәтләү чаралары кеше аңына көчле тәэсир ясарга сәләтле. Хәтта эчтәлекнең тирәнлеген дә шушы ук “төсле” сурәтләү чаралары, аерым төс кулланылышы белән ачып була. Төс бизәкләре поэтик әсәрдә метафорик билгеләмә чарасы буларак та, киң эчтәлекне сыйдырган “мәгънәви күзәнәк” буларак та хезмәт итә.

“Төсле” сурәтләү чараларының татар халык поэзиясендә, аерым алганда, аның гүзәл үрнәкләре булган халык җырларында үз традициясе

бар. Шушы нисбәттән, тарихи җырлар төркеменә мөрәҗәгать итик. Әлеге төркемгә кертелгән җырларда кулланылган төс палитрасын, аның лексик, мәгънәви үзенчәлеген билгеләү өчен, ике дистәдән артык тарихи җыр үрнәкләре сайлап алынып тикшерелде.

Иң беренче итеп, шуны билгеләп үтәргә кирәк: тарихи җырлар төркеменә халыкның үткән тарихындагы аерым социаль-тарихи вакыйгаларга, күренекле шәхесләргә багышланган әсәрләрне кертәләр [И.Надиров, 1988: 5-6 ]. Димәк, тарихи җырларда кулланылыш тапкан төсләр, “төсле” сурәтләү чаралары, төсле образлар аша чорның, шул чорда яшәгән татар халкының тарих битләрендә уелып калачак иҗтимагый вакыйгалар барышындагы психологик атмосферасын ачып бирергә сәләтле дип әйтү һич тә ялгыш булмас.

Тарихи җырлар арасында канкойгыч сугышлар, алардан җәфа чиккән гади халык кайгысы темасы үзәктә тора. Алтын Урда таркалуы, 1773-1775 нчы еллардагы крестьян сугышы, 1812 елгы Ватан сугышы, гражданнар сугышы, Октябрь революциясенә багышланып иҗат ителгән җырларда, билгеле, төп урынны *кара төс* алып тора.

*Кара – тирән кайгы, афәт, фаҗига, траур төсе* булып исәпләнә. Сугыш тематикасын яктырткан җырларда аның башка төсләргә караганда ешрак кулланылышы шуның белән аңлатыла.

*Кара урман, карурман* - татар халык иҗатында, мифологиясендә, бик еш кулланылган символик образ. Тарихи җырларда *карурманга юнәлү, кара урман кичү* кайгылы вакыйгалар, чарасызлык, котылгысыз сынаулар, үлемгә дучар ителүнең символик сурәте булып тора:

*Кара урманнарны* чыккан чакта
Төшеп калды алтын чылбырым;
Әнекәем, монда килсәнә,
Китәм, хәлләремне белсәнә [И.Надиров, 1988: 73 ].

Кара төс *кара таш* метафорик сурәте составында җырда куркыныч янау, котылгысыз үлем мәгънәсен ачып сала:

Юл читендә тора *кара таш*,
Илгә кайтыр микән газиз баш? [И.Надиров, 1988: 83 ].

“Юл читендә тора *кара таш”* дигән юлларда кара таш кабер ташы буларак та күзалланырга мөмкин, бу исә үз чиратында, адым саен үлем куркынычы янау ассоциациясен тудыра. Шулай итеп, бу җырда, *кара* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылып, үлем символы ролен үти дисәк тә була.

Кайбер җыр үрнәкләрендә, кара төс кергән сүзтезмә, туры мәгънәдә килеп, предметның бары тик төс характеристикасын билгеләү өчен кулланыла кебек тоелырга мөмкин:

Казак булып китеп барам,
*Кара каеш* билләрдә;
Я кайтырбыз, я кайтмабыз
Туып-үскән илләргә [И.Надиров, 1988: 75 ].

Әмма, мисалдан күренгәнчә, кара камчат бүрекле Салават Юлаев кебек тарихи шәхес яки ил данын якларга сугышка китүче казак образын сурәтләүдә кулланылган кара төс билгеле бер *затлылык, дәрәҗәлелек* аурасын өстәүче дә булуын аңлыйбыз.

Кара төс янәшәсендә, әлбәттә, ак төсне билгеләү зарур. Борын-борынгыдан алып, халык аңында ак төс билгеле бер мәгънә белән яши. *Ак* - саф, чиста, эчкерсез, пакь, яктылык, тынычлык**,** матурлык, өмет кебек эчке мәгънәгә, уңай ассоциатив эчтәлеккә ия төс [Ә.Шәфигуллина, 2003: 80].

Тарихи җырларда *ак* компоненты кергән җырлар югарыда әйтелгәннәрдән аз гына калыша. *Ак каен, аклы ситса күлмәк, ак яулык* кебек татар халык иҗатында яратып кулланыла торган символлар составында чагылыш таба.

Ак төсне уңай ассоциатив эчтәлеккә ия төс дисәк тә, аерым сүзтезмә составында, мәсәлән, *ак каен* сүзтезмәсендә, ул бу эчтәлекне югалтырга да мөмкин.

*Ак каен*, гомумән, каен агачы татар халык җырларында кайгы-хәсрәт, сагыш-моң символы буларак файдаланыла. Җырдагы лирик герой үз бәхетсезлеген өй артындагы каеннан яки юлда ауган каеннан, каеннан ясалаган киртәләр, балачактагы каен бишектән күрә [К.Миңнуллин, 1999: 28].

*Ак каеннарның* бөресен
Итәгеңә төяп йөрерсең;
Төшләреңдә безне күрсәң дә,
Өннәреңдә елап йөрерсең [И.Надиров, 1988: 74 ].

Югарыдагы мисалда да, *ак каен* образына сагыш, юксыну, югалту кебек эчке мәгънәләр салынган. Сугышка китүчегә эндәш рәвешендә язылган әлеге тарихи җырда ак төс кайгы төсмерен дә йөртүче сүзгә әйләнә.

*Аклы ситса күлмәк һәм ак яулык* кебек символик сурәтләр составында ак төс, гадәттә, уңай ассоциатив эчтәлекне - саф күңеллелек, намуслылык, нәфислек мәгънәсен йөртә.

*Аклы ситса күлмәгемне*
Саламын да киямен;
Минем иркәм – батыр егет,
Шуны өзелеп сөямен” [И.Надиров, 1988: 347 ].

Бу очракта ак күлмәк кию - сугышка киткән сөйгән ярга тугърылыклы булу, намуска тап төшермәү, саф мәхәббәт хисләрен саклауны чагылдыру өчен кулланылган сурәт.

“Сөембикә китеп бара” дип аталган тарихи җырда дәүләте һәм халкыннан аерылырга мәҗбүр ителгән ханбикәнең кулындагы ак яулыгы да тугърылык һәм намусына хыянәт итмәү анты кебек символлаштырыла.

Сөембикә *ак яулыгын*

Тоткан учлап кулына;

“Хуш, казаным, каласың, - дип,

Үкереп елый буена [И.Надиров, 1988: 40 ].

Тарихи җырларда изегелек-явызлык антонимиясен гәүдәләндергән гадәти ак-кара төсләренәннән тыш, *яшел төс* тә куллану ешлыгы буенча өченче урында тора. *Яшел* – яшәү, яшәрү, өмет, тынычлык төсе санала. Татар халык иҗатында яшел төс туган җир, туган ил, туган як табигатен тасвирлауда доминанта ролен үти. Шуңа да туган җиреннән аерылучы яки яу кырларында туган җирен, туган илен сагынып өзгәләнүче лирик геройның кичерешләрен ачып салу өчен кулланыла.

*Хәтфәдәй яшел* булып

Тора микән җир йөзе,

Яндырып бетердеме әллә

Аларны да дошманым?” [И.Надиров, 1988: 40 ].

Димәк, тарихи җырларда яшел төс *яшел хәтфә, яшел болыннарны* лирик геройның күзалдына китерүе туган як, аны сагыну, тыныч тормышка кайту теләген сурәтләү өчен файдаланыла.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: тарихи җырның бары бер үрнәгендә - патша армиясе сафларында егерме биш елга кадәр хезмәт турында ачынып иҗат ителгән халык җырында - яшел компонентының контекст белән билгеләнүче негатив төсмере чагылыш таба:

Башымдагы *яшел картузым*

Алды гомеремнең яртысын! [И.Надиров, 1988: 80 ].

Җырларда, гадәттә, яшьлек, гүзәллек белән ассоциацияләнә торган яшел төс бу очракта, яшел төстәге хәрби кием белән янәшә, патша хезмәтендә гомер уздыручының тискәре уй-кичерешләрен белдерү чарасы, нәфрәт объекты буларак кулланыла.

Тарихи җырлар төркемендә *җирән төс* дә кулланылыш таба. Җирән төскә карата уңай ассоциатив күзаллаулар урнашкан дип билгеләргә кирәк. Җирән төс (кызгылт-сары яки куе сары) – ялкын, кояш төсе, энергия, эмоциональ күтәренкелек, шатлык төсе буларак та санала. Шул ук вакытта игътибарны җәлеп итү яки башкалардан аерылып тору кебек эчке ассоциатив мәгънәне йөртүче төс. Ул *җирән ат* образының бер компонентын тәшкил итә.

Татар җырларында ат - иң актив образларның берсе. Мәсәлән, аргамак, юрга, юртак, акбүз ат, чаптар, туры, җирәнчәк, алмачуар, тулпар, дөлдел, кашка кебек төсен, төрен, токымын белдергән дистәләгән сурәтен очратырга мөмкин. Ат образы кергән җырларның барысында да аңа бәйле төп мотив ярылып ята. Бу - ат белән ир-егетнең бердәмлеге [К.Миңнуллин, 1999: 19].

Татар халык лирикасын тикшерүче И.Надиров җырларда ат һәм егет образларының аерлыгысыз булуын, аларның каһарманлык, хезмәт сөючәнлек, түземлелек символы булуын билгеләп үтә [И.Надиров, 1988:134 ].

Шулай итеп, татар халык иҗатының традицион образы буларак сурәтләгәндә, тарихи җырларда *җирән ат, җирәнчәк* урын ала:

*Җирән атым* уйныйдыр,
Су буйларын буйлыйдыр;
Сакта торган чакларында
Иркәм мине уйлыйдыр [И.Надиров, 1988: 59 ].

Җыр эчтәлегеннән күренгәнчә, җирән төс эмоциональ күтәренкелекне, уңай уй-хисләр генә булдыру теләгән “төсле” сурәтләү чарасы булып тора.

Тарихи җырларда *сары төс* тә аерым урын алып тора. Сары төс гомумсыйфатлары буенча шулай ук көчле энергетик, эмоциональ күтәренке, затлы (алтын төс) булса да, татар халык үзаңында, халык

иҗатында ул сагыш-моң, сагыну-юксыну, шулай ук аерылышу, хыянәт кебек мәгънәне чагылдыра. Мәсәлән, “Ристаннар җыры”нда *сары чәчәк* символик образы кулланыла.

Ристаннар моңаядыр
*Сары чәчәк* атканда,
Нурлы йөзләр саргаядыр
Казаматта ятканда [И.Надиров, 1988: 70 ].

Әлеге мисалда нахакка гаеп ителеп, ирегеннән мәхрүм ителгән ристаннарның кайгы-хәсрәтен чагылдыру өчен сары төс сайлап алынган. Бу күренеш татар халкында сары төсне күңелсез вакыйгалар белән бәйләүгә тагын бер мисал булып тора.

Тарихи җырларда, гадәттә, канлы көрәш, сугыш, яу бару темасы үзәктә булуга карамастан, кан, көч, көрәш төсе булган кызыл төс сирәк искә алына. Мисал өчен, “Качкын җыры”нда:

Алма ярдым, эче *кызыл*дыр
Барачак юлларым озындыр [И.Надиров, 1988: 46 ].

Гадәттә, кызыл алма образы халык җырларында бөтенлек, бәхет, мәхәббәт белән ассоциацияләнә. Ләкин *кызыл эчле алма* кебек сурәттә кызыл төс качкын алдындагы канлы көрәшне фаразлаучы булып тора дип әйтсәк һич тә ялгыш булмас.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, чал тарих битләрендә, халкыбыз хәтерендә, тарихи җырларда уелып калган басып алу яулары, канкойгыч сугышлар, көрәш вакыйгаларын тасвирлауда *кара, кызыл, сары,* аерым бер очракта *яшел* төсләр фаҗига, үлем, кайгы-хәсрәт, сагыш, аерылу, чарасызлык кебек төшенчәләрнең төсле сурәтләре ролен үтиләр. Ак, яшел һәм җирән төсләр уңай сыйфатлар һәм хис-кичерешләрнең (күңел күтәренкелеге, саф күңеллелек, өмет, тынычлык, юаныч һ.б.) ассоциатив мәгънәсен чагылдыралар.

Әдәбият

1. Әхмәдуллин А. Әдәбият белеме сүзлеге / А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар кит. нәшр., 1990. – 238 б.
2. Миңнуллин К. Җырларның шигъри табигате / К.Миңнуллин. - Казан: Мастер Лайн, 1999. – 107 б.
3. Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар / Төз. И. Надиров – Казан: Татар кит. нәшр., 1988. – 485 б.